ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.12.2015 ел Казань ш. № 10-42/кс

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында

Техник хатаны бетерү максаты белән Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «2016 елга эчергә яраклы суга, су бүлүгә һәм ташландык суларны транспортировкалауга тарифлар билгеләү турында» Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2015 елның 11 декабрендәге 10-38/кс санлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

10 пунктның 1 баганасындагы «Яңа Чишмә торак-коммуналь хуҗалыгының күп тармаклы житештеру предприятиесе Ачык акционерлар җәмгыяте»* сүзләрен «Яңа Чишмә торак-коммуналь хуҗалыгының күп тармаклы житештерү предприятиесе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте»*.сүзләренә үзгәртергә.

2. «2016 елга эчергә яраклы суга, техник суга, су бүлүгә, салкын суны транспортировкалауга һәм ташландык суларны транспортировкалауга тарифлар билгеләү турында» Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының 2015 елның 16 декабрендәге 10-40/кс санлы карарының 21 пунктына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

21.3.5 – 21.3.10 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итергә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «21.3.5 | аеруча пычранган ташландык суларны агызу | | | | | 104,62 | 108,93 | | | | |
| 21.3.6 | Өске ташландык суларны хуҗалык-көнкүреш канализациясенә агызу | | | | | 10,12 | 10,69 | | | | |
| 21.3.7 | өске ташландык суларны агызу | | | | | 3,25 | 3,54 | | | | |
| 21.3.8 | сәнәгый ташландык суларны агызу | | | | | 38,44 | 43,88 | | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 21.3.9 | химик ташландык суларны агызу | | | | | 148,16 | 148,16 | | | | |
| 21.3.10 | шламлы ташландык суларны агызу | | | | | 7,02 | 8,07 | | | | » |

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р.Зарипов